**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БӘЙРӘКӘТАМАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР №3

Бәйрәкәтамак ав. 16.02.2026 ел

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Бәйрәкәтамак авыл җирлеге Советының 2021 елның 25 ноябрендәге 11 санлы карары белән расланган "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы “Бәйрәкәтамак авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

В соответствии Федеральным законом от 20.03.2025 № 33-ФЗ «Об общих принципах организации местного самоуправления», Федеральным законом от 06.10.2003 № 131-ФЗ «Об общих принципах организации местного самоуправления в Российской Федерации», Федеральным законом от 31.07.2020 № 248-ФЗ «О государственном контроле (надзоре) и муниципальном контроле в Российской Федерации», Федеральным законом от 26.12.2008 № 294-ФЗ «О защите прав юридических лиц и индивидуальных предпринимателей при осуществлении государственного контроля (надзора) и муниципального контроля», Законом Республики Татарстан от 28.07.2004 №45-ЗРТ « О местном самоуправлении в Республике Татарстан», Уставом муниципального образования «Байряки-Тамакское сельское поселение» Ютазинского муниципального района Республики Татарстан, Совет Байряки-Тамакского сельского поселения Ютазинского муниципального района Республики Татарстан Р Е Ш И Л:

1. Внести в Положение о муниципальном контроле в сфере благоустройства на территории муниципального образования «Байряки-Тамакское сельское поселение» Ютазинского муниципального района Республики Татарстан, утвержденное решением Совета Байряки-Тамакского сельского поселения Ютазинского муниципального района Республики Татарстан от 25.11.2021 № 11 следующее изменения:

1.1. Нигезләмәнең 3.10.5.6 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«3.10.5.6. Әгәр йөкләмәдә контроль төре һәм (яисә) мәҗбүри профилактик визитлар үткәрелергә тиешле контрольдә тотылучы затлар исемлеге күрсәтелмәгән булса, мондый йөкләмәне үтәүне оештыру максатларында 2020 елның 31 июлендәге «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында»гы 248-ФЗ санлы Федераль законның 52.1 маддәсендәге 7 өлеше нигезендә Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе урынбасары йөкләмәсе кабул ителә.»;

1.2. Нигезләмәнең 3.10.6.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«3.10.6.4. Профилактик визит үткәрүдән баш тарту турында карар түбәндәге очракларда кабул ителә:
1) тикшереп торучы заттан гаризаны кире алу турында хәбәр килгәндә;
2) кабат гариза бирү көненә кадәр алты ай эчендә профилактик визит уздыру эшчәнлекне башкару урынында тикшереп торылучы зат булмауга йә тикшереп торылучы затның профилактик визит уздыру мөмкин булмавына китергән башка гамәлләренә (гамәл кылмавына) бәйле рәвештә мөмкин булмаганда;
3) контроль (күзәтчелек) органы гариза биргән көнгә кадәр бер ел эчендә элек бирелгән гариза буенча профилактик визит үткәрелгәндә;

4) гаризада цензурасыз йә мыскыллаучы сүзләр, контроль (күзәтчелек) органы вазыйфаи затларының йә аларның гаилә әгъзаларының гомеренә, сәламәтлегенә һәм мөлкәтенә янаулар булганда.

5) контрольдә тотылучы зат 2020 елның 31 июлендәге "Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында"гы 248-ФЗ санлы Федераль законның 52.2 маддәсендәге 1 өлешендә каралган критерийларга туры килмәгәндә.

1.3. Нигезләмәнең 3.10.5.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.10.5.3. Мәҗбүри профилактик визит контрольдә тотылучы затның аны үткәрүдән баш тартуын күздә тотмый. 2020 елның 31 июлендәге «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында»гы 248-ФЗ санлы Федераль законның 21 маддәсендәге 5 өлешендә каралган тәртиптә контрольдә тотылучы затка мәҗбүри профилактик визит башланырга егерме дүрт сәгатьтән дә соңга калмыйча хәбәр ителә;

1.4. Нигезләмәнең 3.10.5.1 пунктындагы пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«в) Россия Федерациясе субъектының иң югары вазыйфаи заты (региональ дәүләт контроле (күзәтчелек) төрләренә, федераль дәүләт контроле (күзәтчелек) төрләренә карата), аларны гамәлгә ашыру вәкаләтләре Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнарына гамәлгә ашыру өчен тапшырылган, һәм 2020 елның 31 июлендәге «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм » муниципаль контроль төрләре турында»гы 248-ФЗ санлы Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законның 5 маддәсендәге 3 өлешендә каралган очракларда муниципаль контроль төрләренә карата;

1.5. Нигезләмәнең 3.10.5.1 пунктының 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) 2008 елның 26 декабрендәге «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында»гы 294-ФЗ санлы Федераль законның 8 маддәсе нигезендә эшкуарлык эшчәнлегенең аерым төрләрен гамәлгә ашыра башлау турында хәбәр иткән контрольдә тотылган затларга карата. Мондый хәбәрләр тапшырылган эшкуарлык эшчәнлеге төрләре исемлеге контроль рәвеше турындагы нигезләмә белән раслана. Күрсәтелгән очракта мәҗбүри профилактик визит мондый хәбәрнамәне тапшыру көненнән алып алты айдан да соңга калмыйча уздырыла;».

2. Әлеге карарны рәсми рәвештә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (https://pravo.tatarstan.ru) рәсми бастырып чыгару һәм массакүләм коммуникацияләр чаралары сыйфатында теркәлү турында таныклык (Роскомнадзор) һәм “Рәсми Татарстан” дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында http://jutaza.tatarstan.ru/ веб-адрес буенча “Интернет” мәгълүмат-коммуникация челтәрендә урнаштыру юлы белән халыкка җиткерелә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Бәйрәкәтамак авыл җирлеге башлыгы З.М.Әгълиева